СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**

**КАРАРЫ**

**16 октябрь 2020 ел** **№ 16**

**Арча район Советының 2018 елның 14 августындагы 187 номерлы карары белән расланган “Хезмәт (вазыйфа) урынында үз-үзеңне тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия турында Нигезләмәне раслау хакында” карарына үзгәрешләр кертү турында (13.10.2018 ел, № 202, 14.03.2019 ел, № 236, 19.09.2019 ел, № 273 үзгәрешләр белән)**

Кадрлар үзгәрешенә бәйле рәвештә, хезмәт (вазыйфа) урынында үз-үзеңне тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия эшчәнлеген оештыруны камилләштерү максатыннан Арча район Советы карар бирде:

1. Арча район Советының 2018 елның 14 августындагы 187 номерлы “Хезмәт (вазыйфа) урынында үз-үзеңне тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия турында Нигезләмәне раслау хакында” (13.10.2018 ел, № 202, 14.03.2019 ел, № 236, 19.09.2019 ел, № 273 үзгәрешләр белән) карары белән расланган хезмәт (вазыйфа) урынында үз-үзеңне тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия составына үзгәрешләр кертергә һәм аны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары А.Ф.Мөхәммәтовага йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г.Нуриев

Арча район Советының
“16” октябрь 2020 ел, №16
карарына кушымта

Хезмәт урынында үз-үзеңне тоту һәм мәнфәгатьләр каршылыгын
җайга салу таләпләрен үтәү буенча
комиссия составы

Мөхәмmәтова Алсу Фирдәүсовна-Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары, комиссия рәисе;

Гапдерахманова Гүзәл Әдһәмовна-Арча район Советы аппаратының оештыру-гомуми бүлеге башлыгы, комиссия рәисе урынбасары;

Хәкимҗанова Альбина Фәритовна- Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппаратының кадрлар секторы мөдире, комиссия секретаре

Комиссия әгъзалары:
Зарипов Рөстәм Зөфәрович- Г.Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте физик тәрбия укытучысы (килешү буенча);

Насыйбуллин Исрафил Рәхмәтуллович - «ТАТМЕДИА» АҖ «Арча-информ» филиалы директоры (килешү буенча);

Сәгыйтова Ләйсән Гарәфетдиновна-Арча район Советы аппаратының юридик мәсьәләләр буенча бүлеге башлыгы;

Таһиров Айнур Мулланурович-Арча муниципаль районы башлыгы ярдәмчесе;

Хәмидуллина Рәмзия Шәриповна- Арча районы ветераннар (пенсионерлар) иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе (килешү буенча);

Харисов Вакыйф Вәгыйзович-Арча районы профсоюз оешмалары координация советы рәисе (килешү буенча);

Һидиятов Ринат Әлифханович- «Бердәм Россия» партиясенең Арча җирле бүлекчәсе баш белгече, Арча муниципаль районының иҗтимагый советы рәисе (килешү буенча).